| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КӘЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КАЗКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКИЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АКТАНЫШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА |
|---|---|
| 423761, Кәзкәй авылы, Беренче май урамы, 2 айорт | 423761, село Казкеево, ул. Первомайская, дом 2а. |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019г. № 25

Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә салют үткәрү урыннарын билгеләү турында

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, 06.10.2003 ел, №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.12.2018 ел,№1088 «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында " карары нигезендә, гражданнарның гомер һәм сәламәтлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.12.2018 ел, № 1088 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим»,

Карар:

1. 2019 елның 20 декабреннән 2020 елның 8 гыйнварына кадәр Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Пиротехник эшләнмәләр кулланып салют үткәрү өчен урыннар (мәйданчыклар) билгеләргә, социаль өлкәдәге якын-тирә торак объектларына кадәр билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ераклык:

а) Кәзкәй авылыннан көнчыгышка, Тыңламас авылына таба, почта бүлекчәсенә алып баручы җирле грунт юлы янында.

б) көнбатышка Тыңламас авылыннан көтүлеккә алып баручы юл янында.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда яннарында пиротехник эшләнмәләр куллану тыела торган объектлар исемлеген раслау турында" 2007 ел, 30 нчы июль, 346 нчы номерлы карары

4. Яңа ел салютын оештыручылар РФ законнары нигезендә административ җаваплылыкка тартыла дип билгеләргә кирәк.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәзкәй авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М. М. Хурмаев

Кушымта № 1

Актаныш муниципаль районы
Кәзкәй авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 25 номерлы карарына карата

Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда яннарында пиротехник эшләнмәләр куллану тыела торган объектлар исемлеге.

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сәнәгать объектлары: | - тѳзелеш сәнәгате оешмалары |
| 2 | Торак-коммуналь хуҗалык объектлары: | -- торак фонды,<br>- халыкның газ, җылылык һәм электр белән тәэмин итү объектлары |
| 3 | Авыл хуҗалыгы объектлары: | - терлекләр асраучы хуҗалыклар;<br>- ашлык саклау урыннары;<br>- агу химикатларын һәм минераль ашламаларны саклау складлары;<br>- орлык эшкәртү һәм агулау предприятиеләре;<br>- азык әзерләү цехлары;<br>- авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау,технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау гаражлары һәм парклары;;<br>- матди складлар. |
| 4 | Кеше күп була торган объектлар: | - дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары,<br>- мәдәният, спорт,мәгариф, сәламәтлек саклау объектлары,<br>- кибет. |